Приложение №1 к приказу
ГАО ДПО «Институт развития образования
Республики Татарстан»
от 05 июня 2017 г. №227

**«Милли мәгариф: татар әдәбиятын укытуның көнүзәк мәсьәләләре»**
дигән темага фәнни-гамәли конференция турында

**НИГЕЗНАМӘ**

1. **Гомуми нигезләмә (вазгыять).** Әлеге нигезнамә конференциянең фәнни җитәкчесен, статусын, исемен, үткәрүнең максатын, бурычларын билгели; конференцияне оештыру, үткәрү, йомгаклау, бүләкләү тәртибен рәсмиләштерә.

2. **Фәнни-гамәли конференциянең фәнни эчтәлеген** билгеләүгә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе **консультантлык итә**.

3. **Фәнни-гамәли конференциянең статусы:** республикакүләм. Ул 2016нчы елның 12 нче декабрендә Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2383\16 боерыгы белән расланган «Татарстан Республикасында 2030 нчы елга кадәр милли мәгариф үсеше Концепциясе»н гамәлгә кую планының 4.5 пункты куйган бурычны тормышка ашыру чарасы буларак, «2014-2020 нче елларда ТР сы дәүләт телләрен һәм ТРның башка халыклары телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү» ТРсы дәүләт программасы кысаларында алып барыла һәм һәр ел милли мәгариф үсешенең аерым бер мөһим мәсьәләсен ассызыклый

Татарстан Республикасындагы гомуми белем оешмаларында татар әдәбиятыннан башлангыч, төп һәм урта гомуми белем бирү программаларын гамәлгә куючы педагогларны фәнни-гамәли эшчәнлектә берләштерә.

4. **Исеме:** «Татар әдәбиятын укытуның көнүзәк мәсьәләләре» (Алга таба «Конференция»). Конференциянең шулай аталуы укытучыларны да, әдипләрне һәм галимнәрне дә, журналистларны һәм нәшрият хезмәткәрләрен педагогик мирасны үзләштерү, саклау һәм үстерү бурычларын хәл итүдә иҗади эшчәнлеккә әйди, активлаштыра, берләштерә.

5. **«Конференция»нең максаты һәм бурычлары:**

5.1. «Конференция»нең максаты: белем бирүдә федераль дәүләт стандартларын гамәлгә кую чорында әдәбият укыту методологиясен пропагандалау аша укытучыларның профессиональ компетентлылыгын күтәрү.

5.2. «Конференция»нең бурычлары:

- укытучыларның белем бирүдә федераль дәүләт стандартларын гамәлгә куюга әзерлеген активлаштыру;
- «Әдәби уку» һәм «әдәбият» дәресләрендә һәм дәрестән тыш укучыларның танып белү һәм фәнни-тикшеренү эшчәнлеген оештыруда татар мәгърифәтчеләре казанышлары нигезендә *алып барылган* алдынгы тәҗрибә белән уртаклашу.

6. **Конференция»не оештыручылар:**

- Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы;
- Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институтының милли мәгариф лабораториясе (алга таба- Лаборатория);
- «Мәгариф» журналы.

7. **«Конференция»нең катнашучылары:**

- «әдәбият» укыту буенча башлангыч гомуми белем программасын гамәлгә куючы педагогик хезмәткәрләр;
- «әдәбият» укыту буенча төп гомуми белем программасын гамәлгә куючы педагогик хезмәткәрләр;
- «Әдәби уку» һәм «әдәбият» укыту-методик комплектлары авторлары;
- журналистлар;

- нәшрият хезмәткәрләре.

**8. «Конференция»нең эчтәлек юнәлешләре:**

- «Әдәби уку» һәм «Әдәбият» предметын гомуми белем бирү оешмаларында укытуда методологик инновацияләр;
- белем бирүдә федераль дәүләт стандартларын гамәлгә кую чорында «Әдәби уку» һәм «Әдәбият» дәресләренең эффективлылыгын тәэмин итүче педагогик технологияләр (кушымтада дәрес эшкәртмәсе теркәлә).

**9. «Конференция»не үткәрү шартлары һәм тәртибе:**

9.1«Конференция» түбәндәге эш формаларын колачлый:

- методик эшләр бәйгесе;
- фәнни-гамәли конференция.

9.2. «Конференция» 2017 нче елның 15 нче июненнән 24 нче ноябренә кадәр өч этапта оештырыла.

<u>1 нче этап</u> түбәндәге эшчәнлекне колачлый:

- 2017 нче елның **15 нче июненнән 25 нче сентябренә** кадәр урыннарда фәнни эшчәнлек оештырыла.
- 2017 нче елның **25 нче сентябреннән 29 нчы сентябренә** Лаборатория фәнни эшләр бәйгесендә катнашу өчен гаризалар һәм эшләр кабул итә.
- 2017 нче елның **2 нче октябреннән 13 нче октябренә** кадәр кабул ителгән эшләр махсус комиссия - Эксперт советы тарафыннан анализлана, кабул ителгән критерийлар нигезендә бәяләнә. Нәтиҗәләр гомумиләштерелә. «Максатка ярашлы эшләр» исемлеге раслана.

<u>2 нче этап</u> түбәндәге эшчәнлекне колачлый:

- Оештыру комитеты «Максатка ярашлы эшләр» исемлегенә кертелгән хезмәт авторларына 2017 нче елның **23 нче октябреннән 27 нче октябренә** кадәр «Конференция»гә чакыру юллый.
- **Көзге каникул көннәрендә** <u>конференция оештырыла</u>.
- 2017 нче елның **15 нче декабренә кадәр** оештыру комитеты тарафыннан «Конференция» кысасында башкарылган эшләрдән җыентык төзелә.

9.3. «Конференция»дә катнашу өчен гариза һәм эш <u>gayan.1958@mail.ru</u> адресына - электрон тартмага җибәрелә. Хәбәрләшү өчен телефон: 8 927 403 85 14

9.4. Эксперт группа составына кертелә:

- әдәбият галиме (Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе *тәкъдим итә*);
- Республикакүләм танылган татар әдәбияты укытучылары (Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институтының милли мәгариф лабораториясе тәкъдим итә);
- журналист («Мәгариф» журналы редакциясе тәкъдим итә).

**10. Бәяләү критерийлары.** Бәяләү критерийлары Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институтының милли мәгариф лабораториясе утырышында кабул ителә һәм Мәгарифне үстерү институты сайтының «Милли мәгариф үзәге» бүлегендә урнаштырыла.

**11.Йомгаклау.**

11.1. 2 нче этапта катнашучыларның барысына да Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институтының **Катнашучы сертификаты** тапшырыла.

11.2. Җиңүчеләр Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институтының I, II, III дәрәҗә **дипломнары** белән бүләкләнә.

**Искәрмә:**

- һәр дәрәҗәдәге димлом берничәшәр дә була ала;
- 2-3 кешелек автордаш эшләр дә катнаша ала.

11.3.«Конференция» кысасында алып барылган эшчәнлек нәтиҗәләреннән чыгып резолюция кабул ителә. Алдагы елга бурычларны конкретлаштырып, Нигезнамәгә өстәмәләр кертелә.